Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының
Питрәч авыл җирлеге Советының тугызынчы утырышы

Питрәч авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

22 май, 2026 ел № 30

Питрәч авылы

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү турында» 2021 елның 12 апрелендәге 16 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре булган гражданнарны Татарстан Республикасы алдындагы казанышларын тану сыйфатында матди бүләкләү максатында **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Питрәч авыл җирлеге Советы карар кабул итте:**

1. «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү турында» 2021 елның 12 апрелендәге 16 номерлы Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлеге Советы карарына (Питрәч авыл җирлеге Советының 2022 елның 25 октябрендәге 52 номерлы, 2022 елның 29 декабрендәге 63 номерлы, 2024 елның 29 маендагы 101 номерлы, 2025 елның 31 гыйнварындагы 119 номерлы, 2025 елның 22 маендагы 123 номерлы, 2025 елның 30 декабрендәге 18 номерлы карарлары белән расланган үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарга «Татарстан Республикасы дәүләт бүләге өчен муниципаль берәмлекләр башлыкларына, муниципаль хезмәткәрләргә вазыйфаи окладына айлык өстәмә түләүне гамәлгә ашыру тәртибе һәм күләмнәре» 10 нчы кушымта өстәргә (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы
Питрәч авыл җирлеге башлыгы Р.Ә. Сөләйманов

СОВЕТ ПЕСТРЕЧИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

Муниципаль районның Питрәч авыл җирлеге Советы карарына кушымта
22 май, 2026 ел № 30

Питрәч муниципаль районының Питрәч авыл җирлеге Советы карарына 10 нчы кушымта
12 апрель, 2021 ел № 16

Татарстан Республикасы Дәүләт бүләге өчен муниципаль хезмәткәрләргә түләүне гамәлгә ашыру тәртибе һәм аларның вазыйфаи окладына айлык өстәмә күләмнәре

1. Муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладына өстәмә түләү билгеләү өчен нигез булып тиешле документ белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт бүләге булу тора.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт бүләге булган муниципаль хезмәткәрләргә өстәмә вазыйфаи окладның 5 проценты күләмендә билгеләнә.

Аны берничә нигездә алу хокукына ия муниципаль хезмәткәрләргә Татарстан Республикасы Дәүләт бүләге өчен өстәмә муниципаль хезмәткәр сайлавы буенча нигезләрнең берсе буенча билгеләнә.

3. Өстәмә түләүләр ай саен исәпләнә һәм акчалата түләү белән бергә җирле үзидарә органының хезмәткә түләү фонды акчалары исәбеннән түләнә.

4. Өстәмә түләү билгеләү турындагы карарны муниципаль хезмәткәрнең эш урыны буенча җирле үзидарә органы җитәкчесе кабул итә.